ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ
Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 12 » гыйнвар 2017 ел** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ линияле объектлары төзелешен планлаштыру һәм ызанлау проектлары буенча гавами тыңлаулар уздыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы уставы, Арча муниципаль районы Советының 2008 елның 27 декабрендәге 220 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районында гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖнең түбәндәге линия объектлары төзелеше территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектлары буенча гавами тыңлаулар уздырырга (1 нче кушымта):

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Зур Бирәзә авылында югары һәм түбән басымлы газүткәргечне бөҗралау».

1.2 «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Айван авылында югары һәм түбән басымлы газүткәргечне бөҗралау»

1.3 «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Күпербаш авылында югары һәм түбән басымлы газүткәргечне бөҗралау»

1.4 Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Ташкич авылында Һ.Такташ, Г.Тукай урамнарын техник яктан яңадан коралландыру.

1.5 «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Васильева Божаавылында югары һәм түбән басымлы газүткәргечне бөҗралау.

1.6 «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Чүриле авылында югары һәм түбән басымлы газүткәргечне бөҗралау.

1.7 «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Ташкичү авылында Ленин урамын техник яктан яңадан коралландыру».

2. Билгеләргә:

2.1. Гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 15.02.2017 ел, 18.00 сәгатьтә;

2.2. Үткәрү урыны - Арча муниципаль районы башкарма комитеты бинасы, адресы буенча: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт;

2.3. Фикер алышкан мәсьәлә буенча тәкъдимнәр булырга мөмкин Адрес: ТР, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт (эш көннәрендә - 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр);

2.4. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен заявкалар бирү срогы - 14.02.2017 ел (тел. 3-12-44).

3. Арча муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм карарның билгеләнгән тәртибенә туры китереп, билгеләнгән срокларда үткәрергә.

4. Әлеге карарны 2017 елның 16 ф гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Арча муниципаль районы башлыгы И.Г. Нуриев